| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГУЛКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ГУЛКИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№5** **09.02.2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 апрелендәге 03 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулькин авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 апрелендәге 03 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 3 пунктында «, муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 3 бүлектә:

а) 12 пунктның икенче абзацында «, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 ел эчендә ташламаларга хокуктан файдаланучы салым түләүчеләр саны нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларга салым түләүчеләрнең ихтыяҗы һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия салым түләүчеләр саны, яисә салым түләүчеләрнең гомуми саны.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктын өстәргә:

«16.1.Муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрмәү рөхсәт ителә.».

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 08 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 22 августындагы 15 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

2.2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 маендагы 08 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 22 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **С.Д.Инькова**